# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**14 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарның террорлык акты турында белә торып ялган хәбәр иткәннәре өчен ата-аналарның яисә аларны алыштыручы затларның административ җаваплылыгы хакында**

Әлеге Закон 14 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарның хокук бозуларын кисәтүгә юнәлдерелгән һәм ата-аналарның яисә аларны алыштыручы затларның балаларны тәрбияләү вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен административ җаваплылыгын билгели.

1 статья. 14 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарның террорлык акты турында белә торып ялган хәбәр иткәннәре өчен -

кисәтү ясала яисә ата-аналарына яки аларны алыштыручы затларга хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

Бер ел эчендә кабат шул ук гамәлләрне кылган өчен -

ата-аналарга яисә аларны алыштыручы затларга хезмәт өчен түләүнең биштән алып ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

2 статья. Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләр эчке эшләр органнарының урындагы вәкаләтле затлары тарафыннан төзелә.

3 статья. Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы эшләр район (шәһәр) судлары тарафыннан административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта карала.

4 статья. Әлеге Законда каралган хокук бозулар өчен штраф суммалары административ материалларны карау урыны буенча шәһәрләрнең һәм районнарның бюджетларына җибәрелә.

5 статья. Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1999 елның 23 сентябре
№ 2371